ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**26.11.2018**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2413**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы ирекле халык дружинасы халык дружиначыларын бүләкләү шартлары һәм тәртибе турында

«Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә җәмәгать тәртибен саклауны гамәлгә ашыруда катнашучы халык дружиначыларын бүләкләү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы ирекле халык дружинасы халык дружиначыларын бүләкләү шартлары һәм тәртибе турында бирелгән нигезләмәне (кушымтаны) расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районының ирекле халык дружинасы халык дружиначыларына акчалата премия түләү чыгымнарын «Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе О.П. Дёгтевага Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына финанслауны тормышка ашырырга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.В.Старостинга йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сапожников

Зеленодольск муниципаль
районыБашкарма комитетының
2018 елның 26 ноябрендәге 2413
номерлы карарына
кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ ҮЗ ЭШЧӘНЛЕГЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ ИРЕКЛЕ ХАЛЫК ДРУЖИНАСЫ ХАЛЫК ДРУЖИНАЧЫЛАРЫН БҮЛӘКЛӘҮ ШАРТЛАРЫ ҺӘМ ТӘРТИБЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы халык дружинасы әгъзаларын мораль һәм матди кызыксындыру шартларын һәм тәртибен билгели.

1.2. Халык дружиначыларын мораль һәм матди стимуллаштыру чараларын куллану Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 16 октябрендәге ««Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегендә тәртип саклау җәмәгать пунктлары һәм халык дружиналары штабын булдыру турында» 2130 номерлы карары нигезендә, халык дружиналары һәм тәртип саклау терәк пунктлары эшчәнлеген координацияләү буенча штаб (алга таба - Штаб) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.3. Штаб мораль стимуллаштыру чараларыннан түбәндәгеләрне куллана:
- Рәхмәт хаты белән бүләкләү;
- Мактау грамотасы белән бүләкләү .

1.4. Мораль стимуллаштыру чараларын рәсмиләштерү билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

1.5. Штаб матди стимуллаштыру чараларыннан түбәндәгеләрне куллана:
- акчалата премия бирү;
- кыйммәтле бүләк белән бүләкләү.

1.6. Матди кызыксындыру чараларын рәсмиләштерү әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.7. Халык дружинасы әгъзаларын матди кызыксындыру Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан гамәлгә ашырыла.

1.8. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының халык дружиначылары реестрында торучы халык дружиначыларының акчалата

премиясен бүләкләү Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының квартал саен эш нәтиҗәләре буенча күрсәтмәсе белән гамәлгә ашырыла.

1.9. Премия бирү һәр квартал нәтиҗәләре буенча 2019 елның 01 гыйнварыннан башлап елына дүрт тапкыр башкарыла.
Премия өч премия күләмендә бирелә:

- 5000 сум күләмендә беренче премия;
- 4000 сум күләмендә икенче премия;
- 3000 сум күләмендә өченче премия.

1.10. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты күрсәтмәсенә бер ай эчендә халык дружиначыларының дежур торуларын исәпкә алуның җыелма табеле куела, ул предприятие, оешма халык дружинасы командиры тарафыннан имзалана һәм штаб начальнигы, йә аны алмаштыручы зат тарафыннан раслана.

1.11. Предприятие, оешма халык дружинасы командиры халык дружиначыларының эш вакытын исәпкә алу өчен җаваплы итеп билгеләнә. Халык дружинасы командиры халык дружиначыларының исемлекләрен төзи һәм аларның кизүгә чыгуларын исәпкә ала. Халык дружиначылары исемлегендә түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:
- исемлеккә кертү датасы;
- халык дружиначысының фамилиясе, исеме, атасының исеме;
- туу датасы, ае, елы;
- паспорт сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән;
- яшәү урыны буенча теркәве;
- иминият таныклыгы күрсәткечләре;
-ИНН;
- телефон номеры (әгәр булса);
- мәгълүматны алган белгечнең фамилиясе имзасы;
- исемлектән төшереп калдыру датасы;
- халык дружиначысын исемлектән төшереп калдыру турында язманы башкаручы белгечнең фамилиясе имзасы белән.

1.12. Соңгы кизү тору датасыннан 12 ай эчендә яисә Штаб карары нигезендә кизү торуга чыкмау очрагында, халык дружинасы әгъзасы халык дружиначылары исемлегеннән төшереп калдырыла, бер ук вакытта исемлектә бер тоташ линия белән халык дружиначысының мәгълүмат юллары сызыла һәм төшереп калдыру датасы куела.

2. Халык дружиначыларын квартал буенча «акчалата премия» белән бүләкләү шартлары һәм тәртибе:

2.1. Бер квартал дәвамында , кимендә 8 тапкыр кизүгә чыккан дружиначылар, квартал саен акчалата премия алырга хокуклы.

2.2. Кандидатларга премияне бирү өчен предприятиеләрнең, оешмаларның халык дружиналары командирлары кул куйган тәкъдимнәре, квартал тәмамланганнан соң , киләсе айның 10 числосына кадәр Штабка карау өчен җибәрелә.

2.3. Штаб үз утырышында кандидатларның тәкъдимнәрен карый һәм квартал тәмамланганнан соң, киләсе айның 20 числосына кадәр, премия бирү турында карар кабул итә. Халык дружиначыларына акчалата премия бирү датасы Штаб тарафыннан билгеләнә һәм халык дружиначыларына предприятиеләрнең, оешмаларның халык дружиналары командирлары аша җиткерелә.

2.4. Узган квартал өчен халык дружиначыларының акчалата премиясенә документларны рәсмиләштерү 30 көннән артмаска тиеш. Штаб хезмәткәрләре гаебе белән рәсмиләштерүне тоткарлау, әлеге Нигезләмәне бозу булып саналмый.

2.5. Квартал саен акчалата премиягә өстәмә рәвештә халык дружиначылары шулай ук акчалата премия яки аңа тиңләштерелгән кыйммәтле бүләк белән Эчке эшләр органнары хезмәткәрләре көненә, туган көненең юбилей даталарына бүләкләнә ала.

2.6. Эчке эшләр органнары хезмәткәрләре көненә, юбилей датасына акчалата премия халык дружиначылары реестрында ярты елдан да ким булмаган һәм ул кварталда кизүгә уртача 8 тапкыр чыккан халык дружиначысына рәсмиләштерелә.

2.7. Бу төр бүләкләүнең дәлиле булып предприятиеләр, оешмаларның халык дружиналары командирлары тарафыннан халык дружиналары кизү торуын исәпкә алу җыелма табеле тора.

2.8. Халык дружиначыларын Эчке эшләр органнары хезмәткәрләре көненә, туган көненең юбилей датасына акчалата премия белән бүләкләү Штаб әгъзалары инициативасы белән башкарыла һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты боерыгы белән рәсмиләштерелә.

Акчалата премия суммасы 3000 сум күләмендә билгеләнә.

3. Халык дружиначыларын «Рәхмәт хаты» белән бүләкләү шартлары һәм тәртибе

3.1. Халык дружиначысы Рәхмәт хаты (алга таба - Рәхмәт хаты) белән Эчке эшләр органнары хезмәткәре көненә, туган көненең юбилей датасына бүләкләнергә мөмкин.

3.2. Халык дружиначысына Рәхмәт хаты ярты елдан да ким булмаган халык дружиначылары составында булу шарты белән рәсмиләштерелә. Шул ук вакытта ул кварталга 8дән артык кизүгә чыгарга тиеш. Әгәр дружиначы стажы

бер елдан артык булса, кизү тору өчен квартал саен уртача чыгуны исәпләү алдагы 12 ай өчен башкарыла.

3.3. Халык дружиначыларын бүләкләү турында үтенечнамәләр предприятиеләрнең, оешмаларның халык дружиналары командирлары тарафыннан тәкъдим ителә.

3.4. Үтенечнамәдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

- халык дружиначысының фамилиясе, исемен атасының исеме;
- халык дружиначысының яшәү урыны;
- халык дружиначысы эш урыны;
- халык дружинасын дислокацияләү урыны һәм аның исеме;
- халык дружиначысы стажы;
- билгеле бер вакыт эчендә кизүгә чыгу саны;
- халык дружиначысының үз бурычларына мөнәсәбәтен кыскача тасвирлау;
- халык дружиначысы бергәләп эшли торган һәм аның кандидатурасын килештергән полициянең өлкән участок уполномоченныйның яки полициянең башка структур бүлекчәсе җитәкчесенең фамилиясе, инициаллары;
- дружина командирының яисә аны алмаштыручы затның фамилиясе, инициаллары һәм имзасы;
- үтенечнамә төзү датасы.

3.5. Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башлыгының карары чыгарыла.

3.6. Бу төр бүләкләүнең нигезе булып предприятиеләр, оешмаларның халык дружиналары командирлары тарафыннан халык дружиналары кизүләрен исәпкә алуның җыелма табеле тора.

3.7. Халык дружиначысына Рәхмәт хаты Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы карары белән бергә тапшырыла.

4. «Мактау грамотасы» белән халык дружиначыларын бүләкләү шартлары һәм тәртибе:

4.1. Мактау грамотасы белән халык дружиначысы Эчке эшләр органнары хезмәткәре көненә, туган көненең юбилей датасына, Зеленодольск муниципаль районында җәмәгать тәртибен саклауга аерым өлеш керткән өчен бүләкләнә ала.

4.2. Халык дружиначысына Мактау грамотасы 2 елдан да ким булмаган халык дружиначылары составында булу шарты белән рәсмиләштерелә. Шул ук вакытта ул 12 ай эчендә 15тән артык кизүдә торган булырга тиеш.

4.3. Халык дружиначыларын Мактау грамоталары бүләкләү турындагы үтенечнамәләр предприятиеләр, оешмалар халык дружиналары командирлары тарафыннан билгеләнә.

4.4. Үтенечнамәдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

- халык дружиначысының фамилиясе, исемен атасының исеме;
- халык дружиначысының яшәү урыны;
- халык дружиначысының паспорт мәгълүматлары;
- халык дружиначысы эш урыны;
- халык дружинасын дислокацияләү урыны һәм аның исеме;
- халык дружиначысы стажы;
- билгеле бер вакыт эчендә кизүгә чыгу саны;
- халык дружиначысының үз бурычларына мөнәсәбәтен кыскача тасвирлау;
- халык дружиначысы бергәләп эшли торган һәм аның кандидатурасын килештергән полициянең өлкән участок уполномоченныйның яки полициянең башка структур бүлекчәсе җитәкчесенең фамилиясе, инициаллары;
- дружина командирының яисә аны алмаштыручы затның фамилиясе, инициаллары һәм имзасы;

4.5. Мактау грамотасы белән бүләкләү турында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башлыгының карары чыгарыла.

4.6. Бу төр бүләкләүнең нигезе булып предприятиеләр, оешмаларның халык дружиналары командирлары тарафыннан халык дружиналары кизүләрен исәпкә алуның җыелма табеле тора.

4.7. Халык дружиначысына Мактау грамотасы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы карары белән бергә тапшырыла.